# Корбан сарыгын яхшы ашатырга кирәк

31 июль көнне мөселман дөньясы Корбан гаетен билгеләп үтәчәк. Бу көнне күпләр корбан чалдыру турында уйлый башлагандыр.



Илшат Садриев фермасындагы баганада Татарстан байрагы эленеп тора. «Без республикабызның патриотлары бит. Ферма өстеннән очкан вертолет һәм самолеттагы кешеләр монда татарлар эшләгәнен күреп торсын!» – диде фермер.

Рухият

Гөлүзә **Ибраһимова**

### Корбан чалу урыннарында күп кеше җыелмаска тиеш

Коронавирус пандемиясе вакытында Корбан гаетен үткәрү һәм корбан чалу кагыйдәләре белән танышу өчен без Казан мәчетләренең берсе – «Ярдәм»гә юл тоттык. Ул физик мөмкинлекләре чикле кешеләргә, мохтаҗларга ярдәм итүче хәйрия үзәге дә булып тора.

Быел хәзрәтләр COVID-19 коронавирусыннан саклану өчен 65 яшьтән өлкәнрәкләргә Гает намазын мәчеттә түгел, ә өйдә укырга киңәш итә. «Гает намазын мәчеттә уку сөннәт санала. Шулай да кешенең сәламәтлегенә зыян килү куркынычы булса, сөннәтне калдырырга ярый», – диде «Ярдәм» мәчете имамы Рафис хәзрәт Сәйфуллин.

Күркәм гадәткә кергәнчә, Гает намазыннан соң корбан чалу йоласы башланачак. «Узган еллар тәҗрибәсе шуны күрсәтә: корбан чалу урыннарына күп кеше җыела. Бүгенге көндә коронавирус инфекциясе таралмасын өчен күпләп җыелу тыела, шуңа күрә корбан чалу урыннарына килмәскә киңәш итәбез. Кешеләр корбанга сатып алган сарыкның итен «Ярдәм» мәчетенә үзебез алып кайтачакбыз. Икенче көнне ул итне тыныч кына алып китеп булачак. Өйгә китереп бирү хезмәте дә каралган. Сарык сайлатып, кешенең сәламәтлеген куркыныч астына куярга ярамый. Барлык сарыкларның да авырлыгы бертигез диярлек», – дип искәртте хәзрәт.

Мәгълүм булганча, корбанга сарыкны бер кеше исеменнән чалалар, ә сыер, дөя кебек эре терлекне берничә кеше кушылып чалдыра ала.

«Ярдәм» мәчете корбанга дигән сарыкларны Казанның «Сөләйман» мәчете территориясендә урнашкан махсус урында чалдырырга җыена. Ә «Сөләйман» мәчетенә аларны Югары Ослан районының Түбән Ослан авылы фермеры Илшат Садриев хуҗалыгыннан китерәчәкләр.

### «Сарык асрау – профессиям кебек»

Түбән Осланда Илшат Садриевның ферма территориясе койма белән тотып алынмаган, барысы да күз алдында. Бирегә килеп җитүгә безне ике эт каршы алды, кешене куркыту уйларында да юк, уйнарга гына булсын. «Әссәламүгаләйкүм!» – дип, ул арада кара кәләпүш кигән ферма хуҗасы үзе дә күренде.

Монда этләр күп икән, кайсы аяк астында уйнап йөри, кайсы ояларында йоклап ята. Бу кадәр сакчы булганда койманың кирәге дә юк. Фермада, сарыклардан тыш, атлар һәм бер ишәк бар. «Монысын кызык өчен асрыйм», – диде Илшат Садриев ишәккә ишарәләп.

Илшат әфәнде инде ун ел сарык үрчетү белән шөгыльләнә. Ферма төзеп эшли башлавына алты ел, аңа кадәр сарыкларны йорт хуҗалыгында асраган.

– Сарык асрау минем өчен профессия кебек. Әти дә һәрвакыт сарык тотты. Монда элек ташландык урын иде, аны чистарттык һәм ике гектар җирне арендага алдым. Әкрен генә ферма төзедек, терлек санын да арттырдык, – дип сөйләде фермер.

Сарыклар матур булып үссен өчен аларны яхшы ашатырга, вакытында йонын алырга кирәк. Садриев хуҗалыгында җәй көне сарыкларның баш саны биш йөзгә җитә, көзгә бераз кимрәк була икән. Яңа елда сарыклар бәрәнли башлый һәм язга тагын күбәяләр. Сарык бәрәне үсеп җиткәнче бер елга вакыт кирәк, ди хуҗа кеше.

Авыл җирлегендә хуҗасыз калган сарыклар булса, Илшат әфәнде аларны үзенә ала. «Әби-бабайлар үлеп китсә, хуҗасыз калган сарыкларны барып алам. Авылда яшьләр сарык асрарга теләми. Сарык үстерүче кеше эшчән булырга тиеш, чөнки аны карар өчен бик иртә торырга кирәк. Менә җәйге кызуда алар көндез ашамый, йокымсыраган кебек бер урынга җыелып тора. Шуның өчен иртәнге сәгать өчтә торып ашатабыз, аннан кичке дүртләр тулгач кына яхшылап ашый башлыйлар. Ике көтүче һәрвакыт фермада яши, аларга зур җаваплылык йөкләнгән. Бу тирәдә бүреләр күренгәне юк, тик кабан дуңгызлары күп. Караңгы төшкәч, сарык көтүе фермага кайта, ә кабан көтүе кырга чыга. Монда кергән очраклары да булды», – ди фермер.

Илшат әфәнде сүзләренчә, бу эш белән ул табыш алу максатыннан түгел, ә күңел һәм савап өчен шөгыльләнә. Сарык үрчетеп зур табышка өметләнеп булмый, ди ул. Терлек азыгын үзләре әзерли.

– Зур табыш китерсә, Татарстанда сарык үрчетүчеләр күп булыр иде. Аны махсус урында чалдыру, ветеринария таләпләре буенча сату нокталарына илтеп җиткерү – бик чыгымлы. Шуңа күрә шәһәр сәүдә нокталарында хәзер күбесенчә Дагыстан, Волгоград, Саратов кебек төбәкләрдән китерелгән сарык ите тәкъдим ителә. Сарык итенең якынча 30 проценты гына Татарстанда җитештерелгән дип уйлыйм, – дигән фикерләре белән уртаклашты фермер.

Илшат Садриев соңгы елларда татарлар арасында Корбанга терлек чалырга оста кешеләрне табуы кыен икәнлеген дә әйтте.

– Иң авыры – Корбан бәйрәмендә сарык чалырга кеше табу, авыллардан эзләп йөрибез, – диде ул.



С.Камалетдинов фотолары

## Корбан чалу өчен нисаб күләме

Татарстан Диния нәзарәтенең Казыйлар шурасы карары белән быел республикада мөселманнарга корбан чалу өчен нисаб күләме (барлык чыгымнардан һәм әҗәтләрдән тыш) 16 мең сум тәшкил итә.

Корбан чалу көнендә кешенең 16 мең сум акчасы булырга тиеш. Әгәр дә, 16 мең сум акчасы булып та, түләнмәгән 1 мең сум әҗәте бар икән, бу кешенең ирекле 15 мең сум акчасы гына бар дип карала. Санап чыгарганнан соң кешенең 16 меңнән дә азрак акчасы калса, аңа Корбан чалу мәҗбүри түгел.

Әгәр дә гаиләдә баланың ирекле 16 мең сум акчасы бар икән, ул да үз исеменнән корбан чалдырырга хокуклы. Моны ул ата-анасына әйтә ала.

## Өч көн дәвам итә

Корбан чалу бәйрәм намазыннан соң башланып китәчәк һәм махсус урыннарда өч көн дәвам итәчәк.

ТР Министрлар Кабинетының Ветеринария баш идарәсе мәгълүматларыннан күренгәнчә, республикада аларны 55 урында оештырырга мөмкин. Әмма, пандемия аркасында, Диния нәзарәтенең мөхтәсибәтләре тарафыннан аларның саны киметелде. Шул рәвешле, корбан чалырга теләүчеләр моны мөфтиятнең мөхтәсибәтләре карамагындагы 33 мәйданчыкта башкара ала. Шулай ук шәхси цех һәм шәхси хуҗалыкларда да корбан чалырга мөмкин.

КУЛЛАНУЧЫ ХӘБӘРЛӘРЕ

## Лагерь янәшәдә булса, ял итәргә ярый

**«Без Казанда яшибез. Быелгы җәйдә баламны Санкт-Петербургта урнашкан интернациональ лагерьга җибәрергә теләгән идем. Әмма күптән түгел генә баланы башка субъекттагы лагерьга озатырга ярамавын белдем. Бу чыннан да шулаймы?**

**Н.Кирина».**



Р.Гали фотосы

РФ Баш дәүләт санитар табибының 2020 елның 30 июнендәге 16нчы карары белән расланган «Яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралу шартларында балалар һәм яшьләр өчен белем бирү оешмалары һәм башка социаль инфраструктура объектларының эшен оештыру, аларның эчтәлеге һәм төзелешенә карата санитар-эпидемиологик таләпләр» нигезендә, балаларның ялы һәм аларны сәламәтләндерү Россия Федерациясе субъекты чикләрендә аларның фактик яшәү урыны буенча оештырылырга тиеш. Биредә Арктика зонасында яшәгән балалар гына искәрмә була ала.

**Федераль әһәмияткә ия шәһәрләрдә яшәгән балаларның ялын оештыру һәм сәламәтләндерү Россия Федерациясенең алар белән чиктәш субъектларында гамәлгә ашырылырга мөмкин.**